**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет
Алькеевского сельского
поселения
Азнакаевского муниципального
района
Пер.Советский,44а,
423309 Тел. ( 885592) 37-4-23

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге
комитеты

Пер.Советский, 44а
Әлкэй авылы, 423309
Тел. (885592) 37-4-23

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» апреля 2018 ел. № 9

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
«Әлкәй авыл җирлеге» җирдән файдалану һәм
төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»гы
карар проекты буенча гавами тыңлауларны
билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 31 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге Советының 2012 елның 21 апрелендәге 26 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә (06.02.2015
№ 103, 19.09.2015 №3, 04.03.2016 №27 карарлар редакциясендә) нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 февралендәге 69 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әлкәй авыл җирлеге» җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча гавами тыңлауларны билгеләргә. (02.09.2015 №122, 25.11.2016 №44, 04.09.2017 №62 карарлар редакциясендә) (1 нче кушымта).
2. Билгеләргә:
   - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү буенча гавами тыңлауларны оештыручы;
3. - үткәрү вакыты - 2018 елның 01 маеннан 2018 елның 01 июленә кадәр 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр;
4. - үткәрү урыны - Әлкәй авылы, Совет урамы, 34 йорт;
   - 2018 елның 01 июленә кадәр - Әлкәй ав., Совет ур., 44а йорт, Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты турында язма тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертелергә мөмкин булган адрес.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык С.З. Зиннурова